**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19

**ГЛАВА АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

Тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.10.2024 ел** **№ 5**

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр, Алат спиртзаводы, Гәр авылларында гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылында гражданнар җыенын 2024 елның 14 ноябренә 15.00 сәгатькә билгеләргә. Үткәрү урыны – Алан-Бәксәр авылы мәдәният йорты.

1.1 Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алан-Бәксәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2025 елда 800 (сигез йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны Алан-Бәксәр авылы территориясендә түбәндәге эшләр:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмаларын төзекләндереп тору;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
- торак пункт территориясен төзекләндерү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?»

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».»

2. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алат спиртзаводы авылында гражданнар җыенын 2024 елның 14 ноябренә 11.00 сәгатькә билгеләргә. Үткәрү урыны – Алат спиртзаводы авылы, Үзәк урам, 33 йорт каршында.

2.1 Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Алат спиртзаводы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2025 елда 800 (сигез йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны Алат спиртзаводы авылы территориясендә түбәндәге эшләр:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?»

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».»

3. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Гәр авылында гражданнар җыенын 2024 елның 14 ноябренә 12.30 сәгатькә билгеләргә. Үткәрү урыны – Гәр авылы, Үзәк урам, 24 йорт каршында.

3.1 Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Гәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче бәлигъ яшьтәге һәр кешедән 2025 елда 800 (сигез йөз) сум күләмендә узара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны Гәр авылында түбәндәге эшләр:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмаларын төзекләндереп тору;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы? »

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».»

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина